МИНИСТЕРСТВО СПОРТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПОРТ МИНИСТРЛЫГЫ

ПРИКАЗ

БОЕРЫК

08.07.2024 Казан шәһәре № 337

Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының 2020 елның 21 февраленнән 78 нче номерлы боерыгы белән расланган Социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килү-килмәве турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәреш кертү турында

Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча эшне камилләштерү максатларында

**б о е р а м:**

1. Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының 2020 елның 21 февраленнән 78 нче номерлы боерыгы белән расланган (Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының 2020 елның 7 июленнән 199 нчы номерлы, 2021 елның 2 февраленнән 63 нче номерлы, 2022 елның 29 августыннан 376 нчы номерлы боерыклары белән кертелгән үзгәрешләр белән) Социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килү-килмәве турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына, аны яңа редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә (теркәлә).
2. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны министр урынбасары И.З. Садриевка йөкләргә.

Министр В.А.Леонов

Татарстан Республикасы
Спорт министрлыгының
2020 елның 21 февраленнән
78 нче номерлы
боерыгы белән расланган

(Татарстан Республикасы
Спорт министрлыгының
2024 елның 8 июленнән
337 нче номерлы боерыгы
редакциясендә)

Социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килү-килмәве турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. 1.1. Социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләрнең билгеләнгән критерийларга туры килү-килмәве турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең әлеге Административ регламенты (алга таба – Регламент) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 6 сентябреннән 2466-р номерлы күрсәтмәсе, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 27 октябреннән «Иҗтимагый файдалы хезмәтләр исемлеген һәм аларны күрсәтү сыйфатын бәяләү критерийларын раслау турында» 1096 номерлы карары нигезендәТатарстан Республикасы Спорт министрлыгы тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләрнең билгеләнгән критерийларга туры килү-килмәве турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү (алга таба – дәүләт хезмәте) тәртибен һәм стандартларын билгели.

1.2. Гариза бирүчеләр булып 1996 елның 12 гыйнварыннан «Коммерциячел булмаган оешмалар турында» 7-ФЗ номерлы Федераль законның 2 маддәсендәге 2.2 пунктының 1 подпунктында каралган социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар (алга таба – социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар, коммерциячел булмаган оешмалар) тора.

1.3. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә профильләү (мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү варианты мөрәҗәгать итүченең Министрлык тарафыннан уздырыла торган анкета нәтиҗәсендә билгеләнгән билгеләренә туры килә торган билгеләре нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү) үткәрелми.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

2.1. Дәүләт хезмәте атамасы.

Социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләрнең билгеләнгән критерийларга туры килү-килмәве турында бәяләмәләр (алга таба – бәяләмә) бирү.

2.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүче орган атамасы.

Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы (алга таба – Министрлык).

Дәүләт хезмәтен башкаручы – Министрлыкның халыкка физик тәрбия бирү һәм физкультура-савыктыру бүлеге (алга таба – Бүлек).

Дәүләт хезмәте Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге (алга таба – КФҮ) аша күрсәтелми.

2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе.

2.3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр тора:

1) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 26 гыйнварыннан «Коммерциячел булмаган оешмалар – иҗтимагый файдалы хезмәтләр башкаручылар реестры турында» 89 номерлы карары белән расланган Социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешманы иҗтимагый файдалы хезмәтләр башкаручы дип тану турында карар кабул итү кагыйдәләренә 2 нче кушымта нигезендә (алга таба – Кагыйдәләр) социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешма тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләрнең билгеләнгән критерийларга туры килү-килмәве турында бәяләмә

2) бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамә (әлеге Регламентка 2 нче кушымта).

Бәяләмә һәм бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамә Министрлык бланкында рәсмиләштерелә.

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе реестр язмасы булып тормый.

Дәүләт хезмәте нәтиҗәсе Татарстан Республикасының нинди дә булса дәүләт мәгълүмат системасында теркәлми.

2.3.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе гариза бирүчегә алуның ул сайлаган ысулы буенча бирелә (җибәрелә):

язма формада гариза бирүчегә шәхсән тапшырыла яки почта аша;

электрон почта адресына;

электрон документ рәвешендә электрон почта адресы буенча яки Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләре (функцияләре) бердәм порталында (https://www.gosuslugi.ru/) (алга таба – Бердәм портал) (техник мөмкинлекләр булганда) гариза бирүченең шәхси кабинетына яки Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (https://uslugi.tatarstan.ru/) (алга таба - Республика порталы) шәхси кабинетына җибәрелә.

2.3.4. Гариза бирүче дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсен электрон документ нөсхәсе рәвешендә кәгазьдә алырга хокуклы.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен кәгазьдә алу өчен мөрәҗәгать итүче Министрлыкка мөрәҗәгать итә.

2.3.4. Бәяләмә реквизитлары:

номер һәм дата;

карар кабул итүгә вәкаләтле орган атамасы.

2.3.5. Бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамә реквизитлары:

номер һәм дата;

карар кабул итүгә вәкаләтле орган атамасы.

2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү срогы.

2.4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк булган гариза һәм документларны гариза бирүче почта аша яки шәхсән тапшырган очракта, дәүләт хезмәте Министрлык тарафыннан гариза һәм документлар теркәлгән көннән алып 30 көн эчендә күрсәтелә.

2.4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк булган гариза һәм документларны гариза бирүче Бердәм порталда яки Республика порталында гариза бирүченең шәхси кабинеты аша тапшырган очракта, Министрлык тарафыннан дәүләт хезмәте эшләр номенклатурасы һәм Бердәм порталның (техник мөмкинлеге булганда) яисә Республика порталының шәхси кабинетында чагылдырыла торган «Документларны тикшерү» статусы нигезендә гаризага номер бирелгән көннән алып 30 көн эчендә күрсәтелә.

Күрсәтелгән вакыт, Кагыйдәләрнең 6 пункты нигезендә Министрлык тарафыннан сораулар җибәрелгән очракта, 30 көннән дә артыграк булмаган вакытка озайтылырга мөмкин.

Күрсәтелгән карарны кабул итү вакытының озайтылуы турында Министрлык гариза бирүчегә Министрлыкка гариза кергән көннән алып 30 көн эчендә хәбәр итә.

2.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен хокукый нигезләр.

Министрлыкның рәсми сайтында, Бердәм порталда (техник мөмкинлек булганда) һәм Республика порталында түбәндәгеләр урнаштырыла:

дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга сала торган норматив хокукый актлар исемлеге;

дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшерүне гамәлгә ашыру өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр;

дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче Министрлыкның, шулай ук аларның вазыйфаи затларының, дәүләт хезмәткәрләрнең, хезмәткәрләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат.

2.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге.

2.6.1. Гариза бирүче үзе мөстәкыйль рәвештә тапшыра торган дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге.

а) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза):

билгеләнгән форма буенча кәгазьдә документ рәвешендә (әлеге Регламентка 1 нче номерлы кушымта);

Бердәм портал яки Республика порталы аша мөрәҗәгать иткәндә (техник мөмкинлек булганда), әлеге Регламентның 2.6.4 пункты таләпләре нигезендә имзаланган электрон формада (гаризаның электрон формасына тиешле мәгълүматларны кертү юлы белән тутырыла);

б) оештыру документларының күчермәләре;

в) гариза бирүче вәкиленең шәхесен раслаучы документ (Министрлыкка шәхсән мөрәҗәгать иткән очракта бирелә). Бердәм портал яки Республика порталы аша мөрәҗәгать иткәндә (техник мөмкинлек булганда), шәхесне раслаучы документтан белешмәләр, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне электрон формада күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик хезмәттәшлеген тәэмин итә торган инфраструктурада

Идентификацияләү һәм аутентификацияләүнең бердәм системасындагы (ИАБС) хисап язмасын раслаганда тикшерелә.

2.6.2. Гариза бирүче тарафыннан оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтнең иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтү сыйфатын бәяләүнең билгеләнгән критерийларына туры килүен нигезли торган документлар (белешмәләр, характеристикалар, эксперт бәяләмәләре, республика башкарма хакимият органнары каршындагы иҗтимагый советлар бәяләмәләре һ.б.) беркетелергә мөмкин.

Гариза бирүче тиешле иҗтимагый файдалы хезмәт буенча социаль хезмәтләр күрсәтүчеләр реестрына кертелгән очракта, гариза бирүче тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләрнең иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтү сыйфатын бәяләүнең билгеләнгән критерийларына туры килүен нигезли торган өстәмә документлар тапшыру таләп ителми.

2.6.3. Дәүләт хезмәте алу өчен гариза бланкын гариза бирүче Бүлеккә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Гариза бланкының электрон формасы Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган.

2.6.4. Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар гариза бирүче тарафыннан кәгазьдә шәхсән тапшырылырга, почта аша, электрон почта яки Интернет-кабул итү бүлмәсе аша юлланырга мөмкин.

Гариза һәм документлар шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан 2011 елның 6 апреленнән «Электрон имза турында» 63-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләренә туры китереп имзаланган (расланган) электрон документ рәвешендә Бердәм портал (техник мөмкинлек булганда) яки Республика порталы аша тапшырылырга (юлланырга) мөмкин.

Гаризаны Бердәм портал яки Республика порталы аша юллаганда, гариза бирүче аны гади электрон имза белән имзалый.

Гади электрон имза алу өчен гариза бирүчегә ИАБС да теркәлү (аутентификация) процедурасын үтәргә, шулай ук хисап язмасын стандарттан түбән булмаган дәрәҗәгә кадәр расларга кирәк.

Гаризага беркетелгән электрон документлар (документларның электрон образлары), шул исәптән ышаныч кәгазьләре pdf, jpg, jpeg, png, tif, doc, docx, rtf форматларындагы файллар рәвешендә җибәрелә.

2.6.5. Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында тапшырылырга тиешле документлар.

Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында Министрлык тарафыннан түбәндәге белешмәләр сорала:

2013 елның 5 апреленнән «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 44-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 44-ФЗ номерлы Федераль закон) нигезендә төзелгән контрактларны үтәү кысаларында оешманың хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча намуссыз тәэмин итүчеләр реестрында булмавын раслаучы (Татарстан Республикасы буенча Федераль Монополиягә каршы тору хезмәте идарәсе);

гариза бирүче документлар тапшырган айның беренче көненә әлеге иҗтимагый файдалы хезмәт буенча социаль хезмәт күрсәтүләрне тәэмин итүчеләр

реестрына гариза бирүче турында язу кертү турында (Россия Федерациясе Юстиция министрлыгы ).

Гариза бирүче әлеге пунктта күрсәтелгән белешмәләре булган документларны, шул исәптән мөмкинлеге булганда – электрон формада тапшырырга хокуклы.

Гариза бирүченең югарыда күрсәтелгән белешмәләрне үз эченә алган документларны тапшырмавы гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен сәбәп булып тормый.

Әгәр иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтү сыйфатын бәяләү иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтүләрнең социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган сыйфатының Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 22 августыннан 681 нче номерлы карары белән расланган билгеләнгән критерийларга туры килү-килмәве турында бәяләмәләр бирүне Татарстан Республикасында оештыру турындагы Нигезләмәгә кушымта нигезендә Исемлек буенча берничә республика башкарма хакимият органы тарафыннан гамәлгә ашырылса (алга таба – кызыксынган органнар), сыйфатның туры килү-килмәве турында бәяләмә бәяләмә бирү турында гариза кергән кызыксынган орган тарафыннан бирелә. Сыйфатның туры килү-килмәве турында бәяләмә бирү турында гариза кергән кызыксынган орган, кирәк булганда, башка кызыксынган органнардан, шулай ук дәүләт хакимиятенең башка органнарыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә белешмәләр соратып ала.

2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итмәү өчен сәбәпләрнең тулы исемлеге.

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итмәү өчен сәбәп булып түбәндәгеләр тора:

әлеге Регламентның 2.6_пунктында күрсәтелгән документларның тулы булмаган исемлеге тапшырылган;

63-ФЗ номерлы Федераль закон һәм 2010 елның 27 июленнән «Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрне оештыру турында» 210-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба -210-ФЗ номерлы Федераль закон ) таләпләре (гаризаны электрон формада биргәндә) нигезендә гади электрон имза белән имзаланмаган гариза һәм документлар (документларның күчермәләре) тапшыру.

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар Бердәм порталда яисә Республика порталында, Министрлыкның рәсми сайтында бастырылган дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибе турындагы мәгълүмат нигезендә бирелгән очракта, гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны кабул итүдән баш тарту тыела.

2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен сәбәпләрнең тулы исемлеге.

2.8.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен сәбәпләр законда каралмаган.

2.8.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен сәбәп булып түбәндәгеләр тора:

а) иҗтимагый файдалы хезмәтнең Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында билгеләнгән аның эчтәлегенә (хезмәт күрсәтүнең күләме, сроклары, сыйфаты) карата таләпләргә туры килмәве;

б) иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтүдә турыдан-туры катнашучы затларның (шул исәптән оешма хезмәткәрләренең һәм гражданлык-хокукый характердагы шартнамәләр буенча җәлеп ителгән хезмәткәрләрнең) кирәкле квалификациясе (шул исәптән һөнәри белем, тиешле өлкәдә эшләү тәҗрибәсе) булмавы, кирәкле квалификациясе булган затларның саны җитмәве;

в) суд, дәүләт тикшерүе (күзәтчелеге) һәм муниципаль күзәтчелек органнары, башка дәүләт органнары тарафыннан нигезләнгән дип табылган, аның гамәлләренә (гамәл кылмавы) һәм (яки) иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтү белән бәйле оешманың карарына бәяләмә бирү алдыннан ике ел эчендә шикаять булу;

г) оешма турында мәгълүматның ачыклык дәрәҗәсенең һәм һәркем алырлык булуының Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында билгеләнгән таләпләргә (алар булганда) туры килмәү;

д) 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә төзелгән контрактларны үтәү кысаларында хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча намуссыз тәэмин итүчеләр реестрында бәяләмә бирер алдыннан ике ел дәвамында оешма турында мәгълүмат булу;

е) дөрес булмаган мәгълүматлар булган документлар бирү яисә документларны тиешле дәрәҗәдә рәсмиләштереп тапшырмау.

2.8.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар Бердәм порталда яисә Республика порталында, Министрлыкның рәсми сайтында бастырылган дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибе турындагы мәгълүмат нигезендә бирелгән очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту тыела.

2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә гариза бирүчедән алына торган түләү күләме һәм аны алу ысуллары.

Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә.

2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза биргәндә һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чиратта максималь көтү срогы.

2.10.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза биргәндә һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.

2.10.2. Гариза бирүчеләрнең аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән.

2.11. Гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турында соравын теркәү вакыты.

2.11.1. Министрлыкка шәхсән мөрәҗәгать иткәндә теркәү гариза һәм документлар кергән көнне гамәлгә ашырыла. Электрон формада ял (бәйрәм) көнендә кергән гариза ял (бәйрәм) көненнән соң килә торган эш көнендә теркәлә.

2.11.2. Гаризаны Бердәм портал аша (техник мөмкинлек булганда) яки Республика порталы аша җибәргәндә, гариза бирүче гариза биргән көнне Бердәм портал (техник мөмкинлек булганда) яки Республика порталындагы шәхси кабинетында һәм электрон почта аша теркәү номеры һәм гариза бирү датасы күрсәтелгән гаризаның җибәрелүен раслаучы хәбәрнамә ала.

2.12. Дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган биналарга таләпләр.

2.12.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы белән җиһазландырылган биналарда гамәлгә ашырыла.

Гариза бирүчеләрне кабул итү урыннары документлар рәсмиләштерү өчен мебель, мәгълүмати стендлар белән җиһазландырыла.

Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматлары гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның мөмкинлекләре чикләнгән булуын истә тотып урнаштырыла.

2.12.2. Россия Федерациясе законнары нигезендә инвалидларның дәүләт хезмәте күрсәтү урынына тоткарлыксыз керә алуын оештыру максатларында аларга түбәндәгеләр тәэмин ителә:

1) бинага тоткарлыксыз керү һәм алардан чыгу мөмкинлеге;

2) дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урынга барып җитү максатларында биналар буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү, шул исәптән объект хезмәткәрләре ярдәмендә;

3) транспорт чарасына утырту һәм аннан төшерү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып;

4) күрү сәләте һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү функциясе бозылуга ия булган инвалидларны озатып бару һәм аларга ярдәм күрсәтү;

5) инвалидларның хезмәт күрсәтүләргә, тормыш эшчәнлеге чикләүләрен исәпкә алып, тоткарлыксыз үтеп керә алуын тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат йөртүчеләрне тиешенчә урнаштыру;

6) озатып йөртүче этне махсус укытуны раслый торган һәм Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2015 елның 22 июненнән «Озатып йөртүче этне махсус укытуны раслый торган документ формасын һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 386н номерлы боерыгы белән билгеләнгән форма буенча һәм тәртиптә бирелә торган документ булганда озатып йөртүче этне кертү;

7) дәүләт хезмәте күрсәтә торган хезмәткәрләр тарафыннан инвалидларга башка затлар белән беррәттән дәүләт хезмәте алуга комачаулый торган киртәләрне җиңүдә ярдәм күрсәтү.

2.12.3. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларның инвалидлар өчен үтемлелеген тәэмин итү өлешендә таләпләр 2016 елның 1 июленнән соң файдалануга тапшырылган яки капиталь ремонт, реконструкцияләү, модернизацияләү үткән объектларга карата кулланыла.

2.13. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең һәркем өчен мөмкин булуы һәм сыйфаты күрсәткечләре.

2.13.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең һәркем өчен мөмкин булуы күрсәткечләре булып түбәндәгеләр тора:

- документларны кабул итү, бирү алып барыла торган бинаның җәмәгать транспортыннан файдалану мөмкинлеге зонасында урнашкан;

- белгечләрнең, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул ителә торган бүлмәләрнең кирәкле санда булуы;

- мәгълүмати стендларда, Министрлыкның рәсми сайтында, Бердәм порталда (техник мөмкинлек булганда) һәм Республика порталында дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм вакытлары турында тулы мәгълүмат булу;

- дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналардан инвалидларның файдалана алу мөмкинлеге;

- дәүләт хезмәте күрсәтә торган хезмәткәрләр тарафыннан инвалидларга башка затлар белән беррәттән хезмәт күрсәтүләрне алуга комачаулаучы инвалидлар өчен биналардан файдалануны тәэмин итү белән бәйле булмаган башка киртәләрне җиңеп чыгуда ярдәм күрсәтү;

- гаризаны электрон рәвештә бирү мөмкинлеге;

- мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләрен электрон рәвештә алу мөмкинлеге;

- гариза бирүче гариза һәм электрон документлар формасындагы документларын Бердәм портал (техник мөмкинлек булганда), Республика порталы аша тапшырганда, хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен Бердәм порталда (техник мөмкинлек булганда), Республика порталында шәхси кабинет аша электрон рәвештә алу мөмкинлеге.

2.13.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфаты күрсәткечләре булып түбәндәгеләр тора:

1) документлар кабул итү һәм карау вакытларын саклау;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу вакытын саклау;

3) Министрлык белгечләренең әлеге Регламентны бозуларына нигезләнгән шикаятьләрнең булмавы;

4) гариза бирүченең Бүлек хезмәткәрләре белән үзара тәэсир итешүе саны:

гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны биргәндә һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен турыдан-туры алганда – икедән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны почта аша юллаганда – үзара тәэсир итешү булмый (консультацияләрне исәпкә алмыйча).

Гариза бирүче белән бер үзара хезмәттәшлегенең дәвамлылыгы 15 минуттан артмый.

Гариза бирүче күчмә радиотелефон элемтәсе җайланмалары ярдәмендә Бердәм портал (техник мөмкинлек булганда), Республика порталын кулланып, дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатын бәяләргә хокуклы.

2.13.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең барышы турында мәгълүматны гариза бирүче Министрлыкта, Бердәм портал (техник мөмкинлек булганда), Республика порталында шәхси кабинетында алырга мөмкин.

2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә башка таләпләр, шул исәптән:

КФҮтә дәүләт хезмәте күрсәтүнең үзенчәлекләрен һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтүнең үзенчәлекләрен исәпкә алып,

Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә дәүләт хезмәте турында белешмәләр бирү турында.

2.14.1 Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

2.14.2. Гариза бирүче Бүлеккә шәхсән, телефон һәм (яки) электрон почта, почта аша мөрәҗәгать иткәндә, аңа консультация бирелергә мөмкин.

2.14.3. КФҮтә дәүләт хезмәте күрсәтү гамәлгә ашырылмый.

2.14.4. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә гариза бирүче электрон формада түбәндәгеләргә хокуклы:

а) Бердәм порталда һәм Республика порталында урнаштырылган дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында мәгълүмат алырга;

б) Бердәм портал (техник мөмкинлек булганда) яки Республика порталыннан файдаланып, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури булган башка документларны, шул исәптән электрон рәвешләре 210-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба – 210-ФЗ номерлы Федераль закон) 16 маддәсендәге 1 өлешенең $7^2$ пункты белән билгеләнгән документлар һәм мәгълүматны бирергә;

в) электрон формада бирелгән дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаларның үтәлеше барышы турында белешмәләр алырга;

г) дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатын бәяләргә;

д) электрон документ формасында дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алырга;

е) Министрлыкның, шулай ук аның вазыйфаи затларының, дәүләт хезмәткәрләренең карары һәм гамәленә (гамәлсезлегенә) дәүләт хезмәте күрсәткәндә дәүләт хезмәтләре күрсәтүче органнар, аларның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре тарафыннан башкарылган карарларга һәм гамәлләргә (гамәлсезлекләренә) судка кадәр шикаять бирү процессын тәэмин итүче Бердәм портал (техник мөмкинлек булганда) һәм (яки) Республика порталы аша шикаять бирергә.

Гаризаны формалаштыру, башка нинди дә булса формада өстәмә гариза бирү зарурлыгыннан тыш, Бердәм портал (техник мөмкинлек булганда) яки Республика порталында гаризаның электрон формасын тутыру юлы белән башкарыла.

2.14.5. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә «Ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы кулланыла.

2.14.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла.

2.14.7. Дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча һәм комплекслы сорау составында күрсәтелми.

## 3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм үтәү вакытлары

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда һәм төзелгән реестр язмаларында җибәрелгән басмадагы хаталарны һәм хаталарны төзәтү өчен кирәкле дәүләт хезмәте күрсәтү вариантларын үз эченә алган дәүләт хезмәте күрсәтү вариантлары исемлеге.

Дәүләт хезмәте, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән басмадагы һәм язмадагы хаталарны төзәтү бердәм вариантта гамәлгә ашырыла һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүнең күрсәтү сроклары, гариза бирүчеләр категорияләре, түләү күләме һәм тәртибе, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар исемлеге; дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә барлыкка килә торган документлар һәм юридик әһәмиятле гамәлләр белән аерылып торган аерым сценарийлары юк.

3.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча бирелгән документның дубликатын бирү өчен вариантлар исемлеге, шул исәптән мондый дубликатны бирүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документ дубликаты бирелми.

3.3. Гариза бирүчене профильләүнең административ процедурасы тасвирламасы.

Гариза бирүчене профильләү процедурасы гамәлгә ашырылмый.

3.4. Дәүләт хезмәте күрсәткәндәге гамәлләрнең эзлеклелеген тасвирлау.

3.4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) гариза бирүчегә консультация бирү һәм шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә ярдәм күрсәтү;

2) гаризаны кабул итү һәм теркәү;

3) ведомствоара запрослар булдыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү;

4) дәүләт хезмәте нәтиҗәсен әзерләү;

5гариза бирүчегә дәүләт хезмәте нәтиҗәсен бирү (җибәрү);

6) техник хаталарны төзәтү.

3.5. Гариза бирүчегә консультацияләр бирү, гариза бирүчегә шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлкәсендә ярдәм күрсәтү.

Гариза бирүче Бүлеккә шәхсән, телефон аша һәм (яки) почта (шул исәптән электрон почта) аша мөрәҗәгать итәргә, шулай ук Бердәм портал (техник мөмкинлек булганда) яки Республика порталы аша Министрлык сайтында дәүләт хезмәте күрсәтүнең тәртибе турында консультация алу өчен мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Бүлек белгече гариза бирүчегә шул исәптән гариза формасы һәм дәүләт хезмәте алу өчен башкаа мәсьәләләр буенча консультация бирә. Кирәк булганда, Бүлек белгече шул исәптән гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк булган документларны рәсмиләштерү өлешендә ярдәм күрсәтә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көндә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: консультация, тапшырыла торган документларның составы, формасы һәм эчтәлеге буенча, шул исәптән дәүләт хезмәте алу өчен кирәкле документларны тутыру өлешендә искәрмәләр, гражданнар мөрәҗәгатен теркәү журналында консультация бирү (гариза бирүчегә ярдәм күрсәтү) турында язу.

3.6. Гаризаны кабул итү һәм теркәү.

3.6.1. Гариза бирүче шәхсән яки ышанычлы заты аша Министрлыкның чараларны координацияләү, тикшерү һәм корпоратив идарә бүлегенә почта, электрон почта яисә Интернет-кабул итү бүлмәсе аша, Бердәм портал (техник мөмкинлеге булганда) яисә Республика порталы аша гариза бирә ала.

Гариза почта аша заказлы хат итеп җибәрелергә мөмкин.

Электрон рәвештә җибәрелә торган гариза 63-ФЗ номерлы Федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә имзалана (раслана) һәм электрон мәгълүмат саклагычлардан һәм (яисә), «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән файдаланып тапшырыла.

Почта аша заказлы хат яисә электрон формада бирелгән гариза гомуми тәртиптә карала.

3.6.1.1. Бүлек белгече тапшырылган документларның комплектлылыгын әлеге Регламентның 2.6 пункты таләпләренә туры килү-килмәвен тикшерә.

3.6.1.2. Гариза бирүче шәхсән яки ышанычлы заты аша мөрәҗәгать иткәндә, әлеге Регламентның 2.7 пунктында каралган документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булган очракта, Бүлек белгече гариза бирүчегә документларны кабул итүдән һәм гаризаны теркәүдән баш тарту өчен нигезләр булуы турында хәбәр итә һәм, баш тарту өчен ачыкланган нигезләрнең эчтәлеген аңлатып, документларны аңа кире кайтара. Таләп буенча баш тарту язма рәвештә рәсмиләштерелә һәм гариза бирүчегә чараларны координацияләү, тикшерү һәм корпоратив идарә бүлеге аша бирелә.

Гариза һәм документларны почта, электрон почта, Интернет-кабул итү бүлмәсе аша җибәргәндә, Бүлек белгече гариза бирүчегә баш тарту өчен ачыкланган сәбәпләрнең эчтәлеген язмача аңлатып, документларны кире кайтара.

3.6.1.3. Министрлыкның чараларны координацияләү, тикшерү һәм корпоратив идарә бүлеге белгече, документлар кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булмаган очракта, гариза һәм документларны Министрлыкның эш башкару буенча инструкциясендә билгеләнгән тәртиптә терки һәм Бүлеккә карауга җибәрә.

Әлеге Регламентның 3.6.1.1 – 3.6.1.3 пунктларында билгеләнә торган процедуралар гариза һәм документлар Министрлыкка кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: теркәлгән гариза һәм документлар яки дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту.

3.6.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза һәм документларны Бердәм портал (техник мөмкинлеге булганда) һәм Республика порталы аша электрон рәвештә кабул итү.

3.6.2.1. Гариза бирүче электрон формада гариза бирү өчен түбәндәге гамәлләрне башкара:

- авторизацияләүне башкара;
- электрон гариза формасын ача;
- дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган белешмәләрне үз эченә алган электрон гариза формасын тутыра;
- электрон формадагы документларны яки электрон документлар образларын электрон гариза формасына беркетә;
- электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү шартлары һәм тәртибе белән танышу һәм килешү фактын раслый (электрон гариза формасында ризалык турында тиешле билгене куя);
- хәбәр ителгән мәгълүматларның дөреслеген раслый (электрон гариза формасында тиешле билгене куя);
- тутырылган электрон гаризаны җибәрә (электрон гариза формасындагы тиешле төймәгә баса);
- электрон гариза әлеге Регламентның 2.6.4 пунктында күрсәтелгән таләпләр нигезендә имзалана;
- электрон гариза җибәрү турында хәбәрнамә ала.

Формалаштырылган гаризаны формат-мантыйкый яктан тикшерү Бердәм портал тарафыннан автомат рәвештә Министрлык билгеләгән таләпләр нигезендә

гаризаның электрон формасындагы һәр юл тутыру барышында башкарыла. Гаризаның электрон формасында Бердәм портал дөрес тутырылмаган кыр булуы ачыклаганда, гариза бирүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны юкка чыгару тәртибе турында электрон формада турыдан-туры хәбәр итү юлы аша хәбәр бирелә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көндә башкарыла.

Административ процедура нәтиҗәсе булып электрон хезмәттәшлек итү системасы белән Министрлыкка юлланган электрон эш тора.

3.7. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган органнарга ведомствоара сораулар (запрос) булдыру һәм җибәрү.

3.7.1. Гариза бирүче әлеге Регламентның 2.6.5 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырмаган очракта, Бүлек белгече дәүләт хезмәтләре күрсәтүдә катнаша торган органнарга (оешмаларга) әлеге Регламентның 2.6.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлеге нигезендә белешмәләр алу өчен ведомствоара сорау җибәрә.

социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешманың 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә төзелгән контрактларны үтәү кысаларында хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча намуссыз тәэмин итүчеләр реестрында булмавын раслаучы (Федераль Монополиягә каршы хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсе);

гариза бирүче документлар тапшырган айның беренче числосына тиешле иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтүләр буенча социаль хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин итүчеләр реестрына гариза бирүче турында язма кертү турында (Россия Федерациясе Юстиция министрлыгы

Күрсәтелгән органнарга ведомствоара мәгълүмат соравы гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү максатыннан җибәрелә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар әлеге Регламентның 3.6 пунктында каралган процедура тәмамланганнан соң биш көннән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: тиешле органнарга җибәрелгән сораулар (запрослар).

3.7.2. Әлеге Регламентның 2.6.5 пунктында каралган документлар (аларның күчермәләре яисә алардагы белешмәләр) ведомствоара сораулар буенча әлеге документлар үз карамагында булган органнар тарафыннан Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 23 июненнән «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кагыйдәләрен раслау, шул исәптән Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең башкарма органнары һәм (яисә) җирле үзидарә органнары арасында ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлекне оештыруның тәкъдим ителә торган кагыйдәләрен раслау турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларын һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 963 номерлы карары нигезендә электрон рәвештә тиешле ведомствоара сорау җибәрелгән вакыттан алып 48 сәгатьтән дә соңга калмыйча җибәрелә.

Министрлыкка бәяләмә бирү турында гариза кергән очракта, иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтүнең сыйфатын бәяләү Татарстан Республикасында социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләрнең сыйфатын бәяләү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 22 августында кабул ителгән 681 номерлы карары белән расланган билгеләнгән критерийларга туры килү-килмәве турында бәяләмәләр бирүне оештыру турындагы нигезләмә нигезендә берничә республика башкарма хакимият органы, шул исәптән Министрлык тарафыннан гамәлгә ашырыла икән, бәяләмә Министрлыкка бирелә. Министрлык, кирәк булганда, башка кызыксынган органнардан, шулай ук дәүләт хакимиятенең башка органнарыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек итү тәртибендә белешмәләр соратып ала. Ведомствоара сорауга җавап бирү вакыты күрсәтелгән органнарга ведомствоара сорау кергән көннән алып 15 эш көненнән дә артмаска тиеш.

Белешмәләрдән файдалануның максатлары булып гариза бирүче тапшырган документларның дөреслеген билгеләү, шулай ук законнарны һәм гариза бирүченең хокукларын бозуны булдырмаслык карарлар кабул итү тора.

3.8. Дәүләт хезмәте нәтиҗәсен әзерләү.

3.8.1. Министрлык Кагыйдәләрнең 6 пункты нигезендә сораулар (запрослар) җибәргән очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты озайтылырга мөмкин, әмма ул 30 көннән дә артмаска тиеш.

Министрлык социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмага дәүләт хезмәте күрсәтү вакытының озайтылуы турында гариза бирүче сайлаган ысул белән хәбәр итә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган административ процедуралар Министрлыкка гариза кергән көннән алып 30 көн эчендә башкарыла.

Административ процедураларны үтәү нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр тора: гариза бирүчегә дәүләт хезмәтен күрсәтү срогын озайту турында хәбәрнамә.

3.8.2. Бүлек белгече түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

документларны рәсмиләштерүнең дөреслеген тикшерү (тапшырылган документларның форма һәм эчтәлек буенча законнарда билгеләнгән таләпләргә туры килүен, документларда барлык кирәкле имзаларның, мөһерләрнең, реквизитларның булуын, чистартулар, төзәтүләр булмауны тикшерү);

бәяләнә торган хезмәтнең аның эчтәлегенә (күләме, сроклары, күрсәтү сыйфаты) Россия Федерациясе норматив хокукый актларында билгеләнгән таләпләргә туры килүен тикшерү;

җәмгыятькә файдалы хезмәт күрсәтүгә турыдан-туры җәлеп ителгән затларның (шул исәптән оешма хезмәткәрләренең һәм гражданлык-хокукый характердагы шартнамәләр буенча җәлеп ителгән хезмәткәрләрнең) кирәкле квалификациясе (шул исәптән һөнәри белеме, тиешле өлкәдә эш тәҗрибәсе) булу-булмавын, кирәкле квалификациясе булган затлар санының җитәрлек булуын тикшерү;

бәяләмә бирү турында гариза биргәнче алдагы ике ел дәвамында 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә төзелгән контрактларны үтәү кысаларында хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча намуссыз тәэмин итүчеләр реестрында оешма турында мәгълүматның булмавын тикшерү;

бәяләмә бирү турында гариза биргәнче алдагы ике ел дәвамында оешманың суд тарафыннан, дәүләт тикшерүе (күзәтчелеге) һәм муниципаль күзәтчелек органнары, компетенцияләре нигезендә башка дәүләт органнары тарафыннан нигезләнгән дип танылган иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтүгә бәйле гамәлләренә (гамәл кылмавына) һәм (яисә) карарларына шикаятьләрнең булмавын тикшерү;

оешма турында мәгълүматның ачыклыгы һәм аңлаешлылыгы дәрәҗәсенең Россия Федерациясе норматив хокукый актларында билгеләнгән таләпләргә (алар булганда) туры килүен тикшерү;

әлеге Регламентның 2.8 пункты күрсәтелгән дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр булмаган очракта, Кагыйдәләргә 2 нче кушымтадагы форма буенча озата баручы хат һәм бәяләмә проектларын яисә, дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.8 пунктында күрсәтелгән нигезләр булган очракта, әлеге Регламентка 2 нче кушымта нигезендә бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамә әзерләү;

әзерләнгән документлар проектларын килештерү өчен Бүлек башлыгына җибәрү.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар ведомствоара сорауларга җаваплар алган көннән алып биш көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган җәмгыятькә файдалы хезмәт күрсәтүләрнең сыйфатын бәяләү, Бүлек башлыгына килештерүгә юлланган документлар проектлары.

3.8.3. Бүлек башлыгы җавап хаты, бәяләмә яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамә проектларын тикшерә һәм аларны килештерүгә министр урынбасарына җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура әлеге проектлар килештерү өчен Бүлек башлыгына кергән көннән өч көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: министр урынбасарына килештерүгә юлланган җавап хаты, бәяләмә яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамә проектлары.

3.8.4. Министр урынбасары җавап хаты, бәяләмә яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамә проектларын килештерү турында карар кабул итә һәм аларны министрга җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура килештерү өчен әлеге проектлар кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: килештерелгән һәм министрга карау өчен җибәрелгән җавап хаты, бәяләмә яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамә проектлары.

3.8.5. Министр бәяләмә белән җавап хатына яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамә кул кую турында карар кабул итә һәм аларны Бүлек белгеченә юллый.

Бу пункт белән билгеләнгән процедура әлеге Регламентның 3.8.3. пунктында каралган процедура тәмамланганнан соң унбиш эш көне эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: министр имзалаган җавап хаты, бәяләмә яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамә.

3.9. Гариза бирүчегә дәүләт хезмәте нәтиҗәсен бирү (җибәрү).

3.9.1. Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчегә үзе сайлаган ысул нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турында хәбәр итә.

Процедураны үтәү, техник мөмкинлекләр булганда, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып, автомат режимда башкарыла.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура министр озата баручы хатка кул куйган көнне гамәлгә ашырыла.

3.9.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү (җибәрү) тәртибе.

3.9.2.1. Гариза бирүче дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу өчен Министрлыкка мөрәҗәгать иткәндә, Бүлек белгече бәяләмә яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилле хәбәрнамәне гариза бирүче сайлаган ысул нигезендә бирә (җибәрә).

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура түбәндәгечә гамәлгә ашырыла:

бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамәне бирү ысулы итеп почта, электрон почта күрсәтелгәндә – бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамәне рәсмиләштергән һәм теркәгән көнне;

бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамәне шәхсән бирү ысулын күрсәткәндә – гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне.

Процедураларның нәтиҗәсе: бирелгән (җибәрелгән) бәяләмә яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамә.

3.9.2.2. Гариза бирүче дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу өчен Бердәм портал (техник мөмкинлеге булганда) яки Республика порталы аша мөрәҗәгать иткәндә, гариза бирүченең шәхси кабинетына дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган, Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи затының көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган документның электрон рәвеше автомат рәвештә җибәрелә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтүне (бирүдән баш тартуны) раслый торган документка имза салынган көнне башкарыла.

Процедураларны башкару нәтиҗәләре булып, Бердәм порталдан (техник мөмкинлеге булганда) яки Республика порталыннан файдаланып, гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүне (шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту) раслый торган документны җибәрү (тапшыру).

3.10. Техник хаталарны төзәтү.

3.10.1. Дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булган документта техник хата ачыкланган очракта, гариза бирүче Бүлеккә түбәндәгеләрне юллый:

- ирекле формада язылган техник хатаны төзәтү турында гариза (тәкъдим ителә торган форма әлеге Регламентка 3 нче кушымтада бирелгән);

- дәүләт хезмәте нәтиҗәсе буларак гариза бирүчегә бирелгән техник хата булган документ;

- юридик көчкә ия, техник хата булуын раслаучы документлар.

Дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булган документта күрсәтелгән белешмәләрдә техник хатаны төзәтү турында гариза гариза бирүче (вәкаләтле вәкил) тарафыннан

шәхсән, почта (шул исәптән электрон почта) аша яисә Бердәм портал (техник мөмкинлек булганда), яисә Республика порталы аша бирелә.

3.10.2. Документлар кабул итү өчен җаваплы белгеч техник хатаны төзәтү турында гаризаны кабул итүне гамәлгә ашыра һәм теркәлеп бирелгән документлар белән гаризаны терки.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура Министрлыкка гариза һәм документлар кергән көнне башкарыла.

Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә кергән гариза ял (бәйрәм) көненнән соң икенче эш көнендә теркәлә.

Процедура нәтиҗәсе булып кабул ителгән, теркәлгән һәм Бүлек белгеченә карауга юлланган гариза тора.

3.10.3. Бүлек белгече бәяләмәне яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамәне яңадан рәсмиләштерү максатларында:

техник хатаны төзәтү турындагы гаризаны һәм аңа теркәп бирелгән документларны карый;

җавап хаты, яңадан рәсмиләштерелгән бәяләмә яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамә проектларын әзерли;

әзерләнгән документлар проектларын имзалау өчен министрга җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар шушы Регламентның 3.10.2 пунктында каралган процедура тәмамланган көннән алып өч эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: министрга җибәрелгән яңадан рәсмиләштерелгән бәяләмә яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамә белән җавап хаты.

3.10.4. Министр яңадан рәсмиләштерелгән бәяләмә яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилле хәбәрнамә белән җавап хатын килештерү турында карар кабул итә һәм аларны Бүлек белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар әлеге Регламентның 3.10.3 пунктында каралган процедура тәмамланган көннән алып бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: министр тарафыннан имзаланган яңадан рәсмиләштерелгән бәяләмә яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамә белән җавап хаты.

3.10.5. Бүлек белгече гариза бирүчегә техник хатаны төзәтү турындагы гаризада күрсәтелгән элемтә ысулын кулланып, бәяләмәне яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамәне яңадан рәсмиләштерү турында хәбәр итә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар министр җавап хатына кул куйган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: бәяләмәне яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән белдерүне яңадан рәсмиләштерү турында гариза бирүчегә хәбәр итү.

3.10.6. Бүлек белгече яңадан рәсмиләштерелгән бәяләмәне яисә бәяләмә бирүдән (җибәрүдән) баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамәне техник хатаны төзәтү турындагы гаризада күрсәтелгән ысул белән (шәхсән, почта, электрон почта

аша, Бердәм портал (техник мөмкинлек булганда) яисә Республика порталы аша) бирә (җибәрә).

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура:

техник хатаны төзәтү турында гаризада яңадан рәсмиләштерелгән бәяләмәне яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамәне бирү ысулы итеп почтаны (электрон почтаны) күрсәткәндә – яңадан рәсмиләштерелгән бәяләмәне яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамәне рәсмиләштергән һәм теркәгән көнне;

техник хатаны төзәтү турында гаризада яңадан рәсмиләштерелгән бәяләмәне яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамәне шәхсән бирү ысулын күрсәткәндә – гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: бирелгән (җибәрелгән) яңадан рәсмиләштерелгән бәяләмә яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамә.

## 4. Административ регламент үтәлешен тикшерү формалары

4.1. Җаваплы вазыйфаи затларның дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләр билгели торган Регламент нигезләмәләрен һәм башка норматив хокукый актларны саклавын һәм үтәвен, шулай ук аларның карарлар кабул итүен агымдагы тикшерүне гамәлгә ашыру тәртибе.

4.1.1. Министрлыкның вазыйфаи затларының әлеге Регламент нигезләмәләрен һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүгә таләпләрне билгели торган башка норматив хокукый актларны саклау һәм үтәвен, шулай ук аларның карарлар кабул итүен агымдагы тикшерү тиешле административ процедураны үтәү өчен җаваплы зат, Бүлек башлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.1.2. Агымдагы тикшерү Министрлыкның вазыйфаи затлары тарафыннан әлеге Регламент нигезләмәләренең һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләрне билгели торган башка норматив хокукый актларның саклауны һәм үтәлешен тикшерүләр уздыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

Агымдагы тикшерү даими нигездә башкарыла.

4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын планлы һәм планнан тыш тикшерүләр үткәрү тәртибе һәм ешлыгы, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын тикшереп тору тәртибе һәм формалары.

4.2.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын тикшереп тору үз эченә тикшерүләр үткәрүне, гариза бирүчеләрнең хокукларын бозуларны ачыклау һәм бетерүне, Министрлык вазыйфаи затларының карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр булган мөрәҗәгать итүчеләрнең мөрәҗәгатьләрен карауны, карар кабул итүне һәм җаваплар әзерләүне ала.

Административ процедураларның үтәлешен тикшереп тору формалары булып тикшерүләр уздыру тора:

эш алып бару, шул исәптән документлар кабул итү вакытларын һәм тәртибен үтәү;

документларны карау нәтиҗәләренең законнар (әлеге Регламент) таләпләренә туры килүе;

дәүләт хезмәте күрсәтү вакытларын, тәртибен үтәү.

Тикшерүләр уздыру ешлыгы планлы (эш планнары нигезендә гамәлгә ашырыла) һәм планнан тыш (гариза бирүченең конкрет мөрәҗәгате буенча) була.

4.2.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгына һәм сыйфатына планнан тыш тикшерү үткәрү турында карар түбәндәге очракларда кабул ителә:

1) әлеге Регламент таләпләрен һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләрне билгели торган башка норматив хокукый актларны элегрәк ачыкланган бозуларны бетерүне тикшерүгә бәйле рәвештә;

2) Министрлыкның дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы вазыйфаи затларының гамәлләре (гамәл кылмавы) аркасында юридик затларның хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре бозылуга шикаятьләр белән мөрәҗәгать иткәндә.

4.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затларының дәүләт хезмәте күрсәтү барышында алар кабул иткән (гамәлгә ашырган) карарлары һәм гамәлләре (гамәлсезлеге) өчен җаваплылыгы.

Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча, мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылу ачыкланган очракта, гаепле дип танылган дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы вазыйфаи затлар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартыла.

4.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшереп тору , шул исәптән гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары ягыннан, тәртибенә һәм формаларына карата таләпләрне характерлый торган нигезләмәләр.

Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары ягыннан дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшерү дәүләт хезмәте күрсәткәндә Министрлык эшчәнлегенең ачык булуы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм дәүләт хезмәте күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләр (шикаятьләр) карауның судка кадәр карау мөмкинлеге турында тулы, актуаль һәм дөрес мәгълүмат бирү юлы белән тормышка ашырыла.

## 5. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсе $1^1$ өлешендә күрсәтелгән оешмаларның, шулай ук аларның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре, хезмәткәрләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәлсезлекләренә) шикаять бирүнең судка кадәр (судтан тыш) тәртибе

5.1. Гариза бирүчеләрнең Министрлык, Министрлыкның дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган вазыйфаи заты яисә дәүләт гражданлык хезмәткәренең гамәлләренә (гамәлсезлегенә) карата судка кадәр Министрлыкка дәгъва бирү хокукы бар.

Министр тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү белән бәйле кабул ителгәнт карарларга, гамәлләргә (гамәлсезлеккә) шикаятьләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына бирелә.

5.2. Гариза бирүче шикаять белән, шул исәптән түбәндәге очракларда да мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны (запрос), 210-ФЗ номерлы Федераль законның 151 нче маддәсендә күрсәтелгән сорауны (запрос) теркәү вакытын бозу;

2) дәүләт хезмәте күрсәтүнең вакытын бозу;

3) гариза бирүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында бирү яки гамәлләр кылу каралмаган документлар яки мәгълүматлар бирүне яисә гамәлләр кылуны таләп итү;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза бирүчедән Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында тапшыру каралган документларны кабул итүдән баш тарту;

5) әгәр кире кагу өчен сәбәпләр федераль законнар, алар нигезендә кабул ителгән башка Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары белән каралмаган булса, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту;

6) дәүләт хезмәте күрсәткәндә гариза бирүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләү кертүне таләп итү;

7) Министрлык, Министрлыкның вазыйфаи затының, дәүләт гражданлык хезмәткәренең дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталар яисә хәреф хаталарын төзәтүдән баш тартуы яисә шундый төзәтүләрнең билгеләнгән вакытын бозуы;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү вакытын яки тәртибен бозу;

9) әгәр туктату өчен сәбәпләр федераль законнар, алар нигезендә кабул ителгән башка Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары белән каралмаган булса, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору;

10) дәүләт хезмәте күрсәткәндә гариза бирүчедән, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 маддәсе 1 өлеше 4 пунктында каралган очраклардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк булган документларны кабул иткәндә беренчел кире кагу вакытында аларның булмавы яисә дөрес түгеллеге күрсәтелмәгән документлар һәм мәгълүмат таләп итү.

5.3. Шикаять язмача кәгазьдә яисә электрон формада бирелә.

Шикаять почта аша, КФҮ, «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, Министрлыкның рәсми сайты, Бердәм портал, Республика порталы аша җибәрелергә, шулай ук гариза бирүчедән шәхси кабул итү вакытында кабул итеп алынырга мөмкин.

Шикаять кергәннән соңгы эш көненнән дә соңга калмыйча теркәлергә тиеш.

5.4. Шикаять аны теркәгәннән соң 15 эш көне эчендә каралырга тиеш. Министрлык, Министрлыкның вазыйфаи заты яисә дәүләт гражданлык хезмәткәренең гариза бирүчедән документларны кабул итүдән яки җибәрелгән язудагы һәм басмадагы хаталарны төзәтүдән баш тартуга карата шикаять белдергән очракта яисә мондый төр төзәтүләрнең билгеләнгән вакытын бозуга шикаять язган очракта шикаять аны теркәгән көннән алып биш эш көне дәвамында карала.

5.5. Шикаятьтә түбәндәге мәгълүмат булырга тиеш:

1) карарлары яисә гамәлләренә (гамәлсезлегенә) карата шикаять бирелә торган Министрлык атамасы, Министрлыкның вазыйфаи заты яки дәүләт гражданлык хезмәткәренең исеме;

2) гариза бирүченең атамасы, урнашкан урыны, шулай ук элемтә өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта (булган очракта) адресы (адреслары) һәм гариза бирүчегә җавап җибәрелергә тиеш булган почта адресы;

3) Министрлык, Министрлыкның вазыйфаи заты яки дәүләт хезмәткәренең дәгъвалана торган карарлары һәм гамәлләре (гамәлсезлекләре) турында мәгълүмат;

4) гариза бирүче Министрлык, Министрлыкның вазыйфаи заты яки дәүләт хезмәткәренең карары һәм гамәлләре (гамәлсезлеге) белән килешмәгән дәлилләр.

5.6. Гариза бирүче үзенең дәлилләрен раслый торган документлар (булган очракта) яисә аларның күчермәләрен тапшырырга мөмкин.

5.7. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буларак түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны юкка чыгару, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда язуда һәм басмада җибәрелгән хаталарны төзәтү, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары белән алу каралмаган акчалата чараларны гариза бирүчегә кире кайтару рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән карарны кабул иткән көннән соң килә торган көннән дә соңга калмыйча, гариза бирүчегә язмача һәм гариза бирүченең теләге буенча электрон формада шикаятьне карау нәтиҗәләре турында нигезләнгән җавап юллана.

Шикаятьне канәгатьләндерерлек дип таныган очракта, гариза бирүчегә җавапта дәүләт хезмәтен күрсәткән чакта ачыкланган бозуларны кичекмәстән юкка чыгару максатында дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган тарафыннан тормышка ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлык өчен гафу үтенелә һәм алга таба дәүләт хезмәте алу максатында гариза бирүчегә башкарырга кирәк булган эш-гамәлләр турында мәгълүмат бирелә.

5.7. Шикаятьне канәгатьләндерерлек түгел дип тапкан очракта, гариза бирүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләрен күрсәтеп нигезләнгән аңлатма, шулай ук әлеге карарга карата шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

5.8. Шикаятьне карау дәвамында яки нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу яисә җинаять билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карау буенча вәкаләт бирелгән вазыйфаи зат булган барлык материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына юллый.

Социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килү-килмәве турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта

Тәкъдим ителә торган форма

Татарстан Республикасы спорт министры

___________________________________
фамилия, исеме, атасының исеме (булганда)

________________________________
оешма атамасы

___________________________________
адрес (почта һәм (яки) электрон)

___________________________________
телефон номеры (булганда)

ГАРИЗА

Сездән социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешма
_____________________________________________________________________
(социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешма атамасы)

күрсәтә торган җәмгыятькә файдалы хезмәтләр сыйфатының
_____________________________________________________________________
(җәмгыятькә файдалы хезмәт атамасы)

аларны күрсәтү өлкәсендә билгеләнгән критерийларга туры килү-килмәве турында бәяләмә бирүегезне сорыйм.

Оешманың чит ил агенты булмавын һәм аның Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 27 октябреннән «Җәмгыятькә файдалы хезмәтләр исемлеген һәм аларны күрсәтү сыйфатын бәяләү критерийларын раслау турында» 1096 номерлы карары белән расланган иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтү сыйфатын бәяләү критерийларына туры килә торган җәмгыятькә файдалы хезмәтне бер ел һәм аннан да күбрәк күрсәтүен раслыйбыз:

_____________________________________________________________________
_____________________________________________________________________
(җәмгыятькә файдалы хезмәт күрсәтүнең аның эчтәлегенең (күләме, сроклары, күрсәтү сыйфаты) Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында билгеләнгән таләпләренә туры килүен раслау);

_____________________________________________________________________
_____________________________________________________________________
(җәмгыятькә файдалы хезмәтләрне башкаруда турыдан-туры катнашкан затларның (шул исәптән оешма хезмәткәрләренең һәм гражданлык-хокукый характердагы шартнамәләр буенча җәлеп ителгән хезмәткәрләрнең) кирәкле квалификациясе (шул исәптән һөнәри белеме, әлеге өлкәдә эшләү тәҗрибәсе), андый затларның саны җитәрлек булуын раслау)

_______________________________________________________________________________

_______________________________________________________________________________

(җәмгыятькә файдалы хезмәтләр алучыларның аларны күрсәтү сыйфаты белән канәгать булуын раслау (гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр булмау һәм (яки) җәмгыятькә файдалы хезмәтләр күрсәтүгә бәйле оешманың суд, дәүләт күзәтүе (күзәтчелеге) һәм муниципаль күзәтчелек органнары, аларның компетенциясе нигезендә, бәяләмә биргәнче 2 ел эчендә башка органнар тарафыннан нигезләнгән карарлар булмау)

_______________________________________________________________________________

_______________________________________________________________________________

(коммерциячел булмаган оешма турында мәгълүматның ачыклыгын һәм файдалана алу мөмкинлеген раслау)

_______________________________________________________________________________

_______________________________________________________________________________

(оешманың 2013 елның 5 апреленнән «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эш, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә төзелгән контрактларны үтәү кысаларында хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча намуссыз тәэмин итүчеләр реестрында булмавын раслау)

Раслаучы документлар теркәлә:

1. ________________________________________________________________
2. ________________________________________________________________
3. ________________________________________________________________

_______________________________________________________________________________

вазыйфа имза фамилия, исеме, атасының исеме (булганда)

«___» __________ 20__ ел

М.У. (булганда)

Социаль юнәлешле коммерциячел булмаган
оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган
иҗтимагый файдалы хезмәтләр
сыйфатының билгеләнгән критерийларга
туры килү-килмәве турында бәяләмәләр бирү
буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына 2 нче кушымта

Социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешма күрсәтә торган
җәмгыятькә файдалы хезмәтләрнең билгеләнгән критерийларга
туры килү-килмәве турында бәяләмә бирүдән баш тарту хакында
дәлилләнгән хәбәрнамә

Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы җәмгыятькә файдалы хезмәтләр күрсәтүнең сыйфатын бәяләү нәтиҗәләре буенча социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешма

______________________________________________________________________________

(социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешманың тулы атамасы һәм төп дәүләт теркәве номеры)

______________________________________________________________________________

күрсәтә торган түбәндәге җәмгыятькә файдалы хезмәтләрнең

______________________________________________________________________________

(җәмгыятькә файдалы хезмәтләр атамалары)

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

сыйфаты туры килү-килмәве турында бәяләмә бирүдән баш тарта.

Күрсәтелгән җәмгыятькә файдалы хезмәтләр күрсәтүнең сыйфатын бәяләүнең билгеләнгән критерийларына түбәндәге сәбәпләр буенча туры килми:

______________________________________________________________________________.

(критерийларга туры килмәве күрсәтелә)

Татарстан Республикасы __________
спорт министры

/____________________________________
имза   фамилия, исеме, атасының исеме (булганда)

«___» __________ 20__ ел
М.У.

Социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килү-килмәве турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 3 нче кушымта

Тәкъдим ителә торган форма

________________________________________
(дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган атамасы )

________________________________________

________________________________________
(оешманың атамасы, адресы
(почта һәм (яки) электрон почта),
телефон номеры (булганда)

## Техник хатаны төзәтү турында гариза

Социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешма тарафыннан күрсәтелә торган җәмгыятькә файдалы хезмәт күрсәтүнең билгеләнгән критерийларга туры килү-килмәве турында бәяләмә биргәндә җибәрелгән хата турында хәбәр итәм.

____________________________________________________________
(бирелгән документ)

күрсәтелгән:

________________________________________________________________

Дөрес мәгълүматлар:

________________________________________________________________

___________________________________________

Җибәрелгән техник хатаны төзәтүегезне һәм дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булган документка тиешле үзгәрешләр кертүегезне сорыйм.

Түбәндәге документларны терким:

1.
2.

Документның әзерлеге турында миңа хәбәр итүегезне сорыйм:

________________________________________________________________
(хәбәр бирү ысулы)

| ____________ | ____________________________ | _______________________ |
|---|---|---|
| (дата) | (гариза бирүче/вәкиле имзасы) | (Ф.И.Аи.) (атасының исеме-булганда) |

Социаль юнәлешле коммерциячел булмаган
оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган
иҗтимагый файдалы хезмәтләр
сыйфатының билгеләнгән критерийларга
туры килү-килмәве турында бәяләмәләр бирү
буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына кушымта
(белешмә)

**СОЦИАЛЬ ЮНӘЛЕШЛЕ КОММЕРЦИЯЧЕЛ БУЛМАГАН ОЕШМАЛАР КҮРСӘТӘ ТОРГАН ҖӘМГЫЯТЬКӘ ФАЙДАЛЫ ХЕЗМӘТЛӘР СЫЙФАТЫНЫҢ БИЛГЕЛӘНГӘН КРИТЕРИЙЛАРГА ТУРЫ КИЛҮ-КИЛМӘВЕ ТУРЫНДА БӘЯЛӘМӘЛӘР БИРҮ ҺӘМ АНЫ БИРҮНЕ ТИКШЕРҮДӘ ТОТУ ӨЧЕН ҖАВАПЛЫ ВАЗЫЙФАИ ЗАТЛАРНЫҢ РЕКВИЗИТЛАРЫ**

## Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы

| Вазыйфасы | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Министр | (843) 222-81-01 | minsport@tatar.ru |
| Министр урынбасары | (843) 222-81-07 | Ildar.Sadriev@tatar.ru |
| Халыкка физик тәрбия бирү һәм физкультура-сәламәтләндерү эше бүлеге башлыгы | (843) 222-60-49 | Elena.Frolova@tatar.ru |

## Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты

| Адрес | Вазыйфасы | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|---|
| 420014, Казан шәһәре, Ирек мәйданы, 1 нче йорт | Сәламәтлек саклау, спорт һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру мәсьәләләре бүлеге башлыгы | (843) 264-75-92 | Raushan.Zaripov@tatar.ru |